СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

14.09.2016 с. Верхний Услон № 14-137

Югары Ослан муниципаль районының муниципаль вазыйфаларын биләүче затларның, Югары Ослан муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең, Югары Ослан муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр урнаштыру тәртибе турындагы Нигезләмәне Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында раслау һәм аларны бастырып чыгару өчен бөтенроссия массакүләм мәгълүмат чараларына тапшыру турында.

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законны, Россия Федерациясе Президентының «Коррупциягә каршы көрәш өлкәсендә эшчәнлекне оештыруны камилләштерү чаралары турында» 2015 елның 15 июлендәге 364 номерлы Указын үтәү йөзеннән, Югары Ослан муниципаль районы Уставына таянып,

Югары Ослан муниципаль районы Советы

Карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы муниципаль вазыйфаларын биләүче затларның, Югары Ослан муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең, Югары Ослан муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны урнаштыру тәртибе һәм Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгару өчен бу мәгълүматларны гомумроссия массакүләм мәгълүмат чараларына бирү турындагы нигезләмәне расларга(1 нче кушымта).

2. Югары Ослан муниципаль районының муниципаль вазыйфаларын биләүче затларның, Югары Ослан муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм шушы белешмәләрне Югары Ослан муниципаль районы Советы карары белән расланган 51-506 номерлы массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турында нигезләмәне үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Советының Законлылык, хокук тәртибе һәм регламенты буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы М. Г. Зиатдинов

Югары Ослан муниципаль районы Советының
2016 елның «14» сентябреннән
№ 14-137 карарына
1 номерлы кушымта

Югары Ослан муниципаль районының муниципаль вазыйфаларын биләүче затларның, Югары Ослан муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең, Югары Ослан муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру тәртибе һәм бу мәгълүматларны бастырып чыгару өчен гомумроссия массакүләм мәгълүмат чараларына тапшыру турында
Нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә белән Югары Ослан муниципаль районы муниципаль вазыйфаларын биләүче затларның, Югары Ослан муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең, Югары Ослан муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләренең, аларның тормыш иптәшләренең һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне урнаштыру тәртибе билгеләнә (алга таба - керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм йөкләмәләре турында белешмәләр Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында (алга таба - рәсми сайт), шулай ук бу мәгълүматларны гомумроссия массакүләм мәгълүмат чараларына (алга таба гомумроссия массакүләм мәгълүмат чаралары) аларның сорауларына бәйле рәвештә бастырып чыгару өчен бирү тәртибе билгеләнә.

2. Рәсми сайтта гомумроссия массакүләм мәгълүмат чараларына керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында түбәндәге мәгълүматлар урнаштырыла:

а) әлеге Нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән затларга милек хокукында яисә алардан файдаланудагы күчемсез мөлкәт объектлары исемлеге, аларның һәркайсының урнашу төре, мәйданы һәм иле күрсәтелә;

б) әлеге нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән затларга милек хокукындагы транспорт чаралары төре һәм маркалары күрсәтелгән транспорт чаралары исемлеге;

в) әлеге Нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән затларның декларацияләнгән еллык кереме.

г) җир кишәрлеге, күчемсез мөлкәтнең башка объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар сатып алу буенча алыш-бирешләр башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы хисап чорына кадәрге соңгы өч елда әлеге Нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән затларның гомуми кеременнән артып китсә.

3. Рәсми сайтта урнаштырыла торган һәм гомумроссия массакүләм мәгълүмат чараларына керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне бастырып чыгару өчен бирелә торган белешмәләрне күрсәтү тыела:

а) әлеге Нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән затларның милек хокукындагы мөлкәте турында һәм аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында

керемнәре турында (әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгәннәрдән гайре) башка белешмәләр;

б) әлеге Нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән затларның хатынының (иренең) яисә балаларының һәм гаиләсенең башка әгъзаларының шәхси күрсәткечләре;

в) яшәү урынын, почта адресын, телефонын һәм әлеге Нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән затлар коммуникацияләренең башка индивидуаль чараларын билгеләргә мөмкинлек бирә торган күрсәткечләр;

г) әлеге Нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән затларга милек хокукында яисә алардан файдаланудагы күчемсез мөлкәт объектларының урнашу урынын билгеләргә мөмкинлек бирә торган күрсәткечләр;

д) дәүләт серенә кертелгән яисә конфиденциаль булган мәгълүмат.

4. Әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләр Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында аларны бирү өчен билгеләнгән срок тәмамланганнан соң 14 эш көне эчендә урнаштырыла.

5. Әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында рәсми сайтта белешмәләр урнаштыру:

Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы, Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы урынбасары, Контроль-хисап Палатасы рәисе, авыл җирлекләре башлыклары, Иннополис шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе, авыл җирлекләре Советы депутатлары, Совет, Иннополис шәһәре, авыл җирлекләре муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан Югары Ослан муниципаль районы Советы аппаратының оештыру бүлегенең вазыйфаи заты тарафыннан тәэмин ителә.

Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты муниципаль хезмәткәрләре, финанс-бюджет палатасы, мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисләре һәм муниципаль хезмәткәрләре, Югары Ослан муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләре тарафыннан тәкъдим ителгән Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлеге вазыйфаи заты тарафыннан тәэмин ителә.

6. Югары Ослан муниципаль районы Советы һәм Башкарма комитетының оештыру бүлекләренең вазыйфаи затлары:

а) гомумроссия массакүләм мәгълүмат чараларыннан сорау алынган көннән алып 3 көн эчендә аның турында Югары Ослан муниципаль районы муниципаль вазыйфасын биләүче затка, муниципаль хезмәткәргә, муниципаль учреждение җитәкчесенә запрос кергән муниципаль учреждение җитәкчесенә хәбәр итәләр;

б) гомумроссия массакүләм мәгълүмат чараларыннан сорау алынган көннән алып 7 көн эчендә аңа әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне бирүне тәэмин итәләр, шул очракта, соралган белешмәләр рәсми сайтта булмаса.

7. Югары Ослан муниципаль районы Советы һәм Башкарма комитетының оештыру бүлекләренең вазыйфаи затлары әлеге Нигезләмәне үтәмәгән, шулай ук дәүләт серенә кертелгән яисә конфиденциаль булган белешмәләрне фаш иткән өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы М. Г. Зиатдинов